КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 11 май г.Казань № 318

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 31 октябрь, 965 нче, 2018 ел, 29 декабрь, 1262 нче, 2019 ел, 6 май, 380 нче, 2019 ел, 11 июль, 565 нче, 2019 ел, 28 август, 714 нче, 2019 ел, 2 ноябрь, 1008 нче, 2019 ел, 30 декабрь, 1278 нче, 2020 ел, 16 апрель, 294 нче, 2020 ел, 21 май, 413 нче, 2020 ел, 1 сентябрь, 772 нче, 2020 ел, 23 октябрь, 954 нче, 2021 ел, 26 июль, 645 нче, 2021 ел, 6 сентябрь, 821 нче, 2021 ел, 29 октябрь, 1021 нче, 2021 ел, 30 октябрь, 1030 нчы, 2022 ел, 15 июнь, 566 нчы, 2022 ел, 22 сентябрь, 1027 нче, 2023 ел, 11 март, 232 нче, 2023 ел, 19 август, 989 нчы, 2023 ед, 16 октябрь, 1312 нче, 2023 ел, 31 октябрь, 1377 нче, 2023 ел, 7 ноябрь, 1431 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

VI бүлектә:

2 пунктта:

3 нче таблицага түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| "3. | Олимпия резервының спорт юнәлешендәге урта звено (төркемнәр, бүлекләр) белгечләре әзерләү программалары буенча һөнәри белем бирү оешмаларында эшләү | тренер-укытучы | - | 7,0»; |

2.3 пунктчада:

беренче абзацта «дәүләт бүләкләре» сүзләреннән соң «(спорт исемнәре)» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацка «(спорт исемнәре)» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Физик культура хезмәткәрләренә һәм тренер-укытучыларга олимпия резервының спорт юнәлешендәге урта звено (төркемнәр, бүлекләр) белгечләре әзерләү программалары буенча һөнәри белем бирү оешмаларында түләүләр бирелгән дәүләт бүләкләре (спорт исемнәре) исемлеге әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтаның 4 нче таблицасында китерелгән.»;

2.3.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3.1. Дәүләт бүләкләренә (спорт исемнәренә) ия булган өчен түләүләр күләмнәрен билгеләү дәүләт бүләге (спорт исеме) бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк дәүләт бүләкләре (ике һәм аннан күбрәк спорт исемнәре) булган мәгариф хезмәткәрләренә алар өчен түләү мәгариф хезмәткәренең сайлавы буенча нигезләрнең берсе буенча билгеләнә.»;

түбәндәге эчтәлекле 2.5 пунктча өстәргә:

«2.5. Югары сыйфатлы укыту-тренировка процессын тәэмин итү өчен түләүләр уңышлы чыгышлар һәм халыкара, бөтенроссия, округ һәм республика ярышларында спортчылар ирешкән нәтиҗәләр өчен, хезмәткәр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторларын үтәүне исәпкә алып, инструктор-методистларга (өлкәннәрне дә кертеп) бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә: ($B_{vytp}$)

$$B_{vytp} = O_d \times \frac{D_{vytp}}{100\%},$$

монда:

$O_d$ - һөнәри белем бирү оешмаларының физик культура һәм спорт хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{vytp}$ - югары сыйфатлы укыту-тренировка процессын тәэмин итү өчен өстәмәләр күләме, ул 51 нче таблицада китерелгән.

2.5.1. Югары сыйфатлы укыту-тренировка процессын тәэмин итү өчен түләүләр, спортчы күрсәткән нәтиҗәгә китергән вакыттан алып, ярышлар беркетмәсеннән өземтә нигезендә бер календарь ел дәвамында билгеләнә.

2.5.2. Югары сыйфатлы укыту-тренировка процессын тәэмин итү өчен түләүнең гамәлдә булу вакыты бер календарь елга билгеләнә.

2.5.3. Югары сыйфатлы укыту-тренировка процессын тәэмин итү өчен өстәмәләр күләме спортчы, спортчы-инструктор тарафыннан программа рәвешендә

шәхси зачетта күрсәтелгән һәр дәрәҗәдәге ярышларда (спортчының иң күбе сигездән артмаган ярышларында) күптөрле ярышларда иң яхшы нәтиҗә яки команда ярышларында нәтиҗә өчен, әгәр мондый ярышларда медаль комплектлары уйнатылса, процентлар суммасыннан формалаша.

5 нче таблица

Югары сыйфатлы укыту-тренировка процессын тәэмин итү өчен өстәмәләр күләме

(процент)

| Квалификация дәрәҗәсе | Ярышлар дәрәҗәсе | Яулан-ган урын | Өстәмә түләү күләме | |
|---|---|---|---|---|
| | | | олимпия спорт төрләре, олимпия дисциплиналары | олимпия булмаган спорт төрләре, олимпия булмаган дисциплиналар |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Икенче | Олимпия уеннары | 1 – 6 | 4,0 | - |
| | дөнья чемпионаты | 1 – 6 | 4,0 | 3,5 |
| | Дөнья кубогы, Европа чемпионаты | 1 – 6 | 3,5 | 3,0 |
| | Европа кубогы | 1 – 4 | 3,5 | 3,0 |
| | Россия чемпионаты | 1 – 4 | 3,0 | 2,5 |
| | Россия кубогы | 1 – 4 | 3,0 | 2,5 |
| | дөнья, Европа беренчелеге | 1 – 6 | 3,5 | 3,5 |
| | Россия беренчелеге | 1 – 3 | 2,5 | 2,5 |
| | Яшьләр, укучылар спартакиадасының финалы | 1 – 3 | 2,0 | 2,0 |
| Өченче | Олимпия уеннары | 1 – 6 | 5,0 | - |
| | дөнья чемпионаты | 1 – 6 | 5,0 | 4,0 |
| | Дөнья кубогы, Европа чемпионаты | 1 – 6 | 4,0 | 3,5 |
| | Европа кубогы | 1 – 4 | 4,0 | 3,5 |
| | Россия чемпионаты | 1 – 4 | 3,5 | 3,0 |
| | Россия кубогы | 1 – 4 | 3,5 | 3,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | дөнья, Европа беренчелеге | 1 – 6 | 3,5 | 3,5 |
| | Россия беренчелеге | 1 – 3 | 3,0 | 3,0 |
| | Яшьләр, укучылар спартакиадасының финалы | 1 – 3 | 2,5 | 2,5»; |

5 пунктның 5.4 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтаның 4 нче таблицасы исеменә «физик культура» сүзләреннән соң «һәм тренер-укытучыларга» сүзләрен өстәргә.

2. Бу карарның гамәле 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин